# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“08” ноябрь 2024 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 08 ноябрендә “Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Өҗем торак пункты территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачлар һәм куаклар кисү, үләннәр чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

2. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү ("Әлия чишмәсе" һәм "Ат чишмәсе"чишмәләрен төзекләндерү (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

«РИЗА» «КАРШЫ»

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 129 (йөз егерме тугыз) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 69 (алтмыш тугыз) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

“Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 69 (алтмыш тугыз) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “Сез 2025 елда яшәү урыны буенча Татарстан республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешегә,

көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, махсус хәрби операциядә һәлак булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1. Торак пункт территориясен төзекләндерү (Иске Өҗем торак пункты территориясен төзекләндерү һәм чистарту (агачлар һәм куаклар кисү, үләннәр чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү));

2. Җир асты суларының табигый чыгу урыннарын (чишмәләрне) төзекләндерү ("Әлия чишмәсе" һәм "Ат чишмәсе"чишмәләрен төзекләндерү (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)) – мәсьәләсен кабул итәргә.

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Өҗем авыл җирлеге Иске Өҗем авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Өҗем авыл җирлеге башлыгы Вәлиев А.Т.